ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» июня 2024 ел № 170

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2021 елның 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, 30.12.2005 елның 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы административ комиссиясенең яңа составын раслау турында» 05.07.2021 елның 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2021 елның 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.12.2023 елның 397 номерлы карарын үз көен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2021 елның 208 номерлы карарына 1 нче кушымта
(19.06.2024 елның 170 номерлы карар редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Административ комиссиясе составы**

1. Салихов Илгиз Хәйдәрович - **административ комиссия рәисе**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Лукшин Павел Алексеевич - **административ комиссия рәисе урынбасары**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палаталарын контрольдә тоту һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы (килешү буенча);
3. Гатауллина Алсу Риназовна - **административ комиссиянең җаваплы секретаре**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге баш белгече.

**Комиссия әгъзалары**:

4. Иманова Любовь Сергеевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча);
5. Самсонова Екатерина Федоровна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы газетасының «Татмедиа» АҖ филиалының дубляж буенча баш мөхәррир урынбасары (килешү буенча);
6. Ниязов Эрнест Фәхретдинович – Җәмәгать Советы әгъзасы (килешү буенча);
7. Гайсина Роза Салиховна - Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары - Татарстан Республикасы Әгерҗе районының бюджет бүлеге башлыгы (килешү буенча).